| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

22.10.2019 Алабуга шәһәре № 409

**2007 елның 2 ноябрендәге 135 санлы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Алабуга муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 31 маддәсе, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советы

КАРАР кабул итте:

1. 2007 елның 2 ноябрендәге 135 санлы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Алабуга муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3.3. пунктның Нигезләмәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Район Советы үзенең якындагы утырышында гражданнарның җыелышын, конференциясен үткәрү турындагы тәкъдимне карый. Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча Район Советы җыелыш яки конференция үткәрүне билгели яки аны үткәрүдән баш тарта. Әгәр җыелыш, конференция үткәрү тәкъдиме һәм максаты Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Алабуга муниципаль районы Уставына, әлеге Нигезләмәгә туры килмәсә, Район Советы җыелыш үткәрүдән баш тарта ала ».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары З.Х.Сөнгәтуллина